| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2020 Казан ш. № 428-12/э-2020

«Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2017 № 3-14/э карары белән билгеләнгән озак сроклы аерым тарифларга 2021 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Ваклап сату (куллану) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә кирәкле тулай табышны озак сроклы индексацияләү алымын кулланып билгеләнә торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау хакында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендәге челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисап ясау өчен электр энергиясе тапшыру буенча хезмәт күрсәтүгә озак сроклы аерым тарифларга һәм җайга салынулы оешманың кирәкле тулай табышына 2021 ел өчен төзәтмә кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте белән «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләрен күрсәтүгә 2018-2022 елларга аерым

тарифлар билгеләү турында» 15.12.2017 №3-14/э карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 30.11.2018 № 3-5/э, 11.12.2019 № 3-6/э карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

атамасында «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләрен «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

3 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
15.12.2017 № 3-14/э
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
15.12.2020 №428-12/э-2020
карары редакциясендә)

«Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте белән «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүгә 2018 елның 1 гыйнварыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмаларының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте – «Сетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2018 | 144 270,55 | 106,27 | 1,03229 | 144 270,55 | 110,52 | 1,03654 |
| | | 2019 | 152 085,78 | 110,81 | 1,08699 | 152 085,78 | 118,45 | 1,09463 |
| | | 2020 | 131 956,36 | 118,56 | 0,96553 | 131 956,36 | 118,56 | 0,96553 |
| | | 2021 | 133 566,78 | 131,00 | 0,98831 | 133 566,78 | 131,00 | 0,98831 |
| | | 2022 | 158 753,28 | 127,79 | 1,14677 | 158 753,28 | 132,90 | 1,15188 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2017 № 3-14/э
карарына 3 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.12.2020 № 428-12/э-2020)
карары редакциясендә)

2018-2022 елларга «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыятенең кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтуларны исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының кирәкле тулай табышы, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | «Электросетевая компания» акционерлык җәмгыяте | 2018 | 12 980,89 |
| | | 2019 | 13 684,07 |
| | | 2020 | 11 872,91 |
| | | 2021 | 12 017,80 |
| | | 2022 | 14 283,98 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге